КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 февраль г.Казань № 60

2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен раслау турында

Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына «Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасы катнашында 2021 елның 1 мартына кадәр әлеге карар белән расланган Концепцияне гамәлгә ашыру чаралары планын эшләргә һәм раслау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2011 - 20125 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2011 ел, 29 ноябрь, 970 нче;

«2016 - 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен раслау турында» 2016 ел, 08 апрель, 206 нчы;

«2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2017 ел, 15 февраль, 86 нчы;

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 6 февраль, 60 нчы
карары белән расланды

# 2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясендә (алга таба – Концепция) Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясен үстерүнең төп максатлары һәм бурычлары, проблемаларның эчтәлеге һәм аларны хәл итү, шулай ук Концепцияне гамәлгә ашыру механизмы формалаштырылды.

1.2. Үз максатлары һәм бурычлары буенча Концепция «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе белән интеграцияләнде.

1.3. Кулланучылар кооперациясе дигәндә әлеге Концепциядә «Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-I номерлы Россия Федерациясе Законы һәм Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә төзелә һәм эшли торган кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре системасы, кулланучылар кооперациясенең башка оешмалары системасы аңлашыла.

1.4. Татарстан Республикасында кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре системасы, кулланучылар кооперациясенең әзерләү, җитештерү һәм сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм авыл торак пунктларында яшәүчеләргә төрле хезмәтләр күрсәтүче башка оешмалары системасы кулланучылар кооперациясе системасы булып тора.

1.5. Концепцияне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында әзерләү, җитештерү һәм сәүдә эшчәнлеген үстерүдә кулланучылар кооперациясе оешмаларының ролен арттыруны тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында яшәүчеләрнең хезмәт белән тәэмин ителешен күтәрүгә ярдәм итәргә тиеш.

## II. Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерүнең төп максатлары - авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималын әзерләү, җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру, шулай ук авыл торак пунктларында яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту.

2.2. Концепция хәл итүгә юнәлдерелгән төп мәсьәләләр

авыл торак пунктларында яшәүчеләргә күрсәтелә торган, шул исәптән хәзерләү, җитештерү һәм сәүдә эшчәнлеге буенча хезмәтләрнең гомуми күләмен арттыру;

кабул итү-хәзерләү пунктлары челтәрен арттыру һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чимал хәзерләү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру;

үз продукциясен җитештерү һәм реализацияләү күләмнәрен арттыру;

җитештерү егәрлекләренең максималь йөкләнешен тәэмин итү;

авыл торак пунктларында яшәүчеләргә күрсәтелә торган ваклап сатудагы товар әйләнеше, көнкүреш хезмәтләре күләмнәрен арттыру;

кулланучылар кооперациясе оешмалары хезмәткәрләренең эшлекле активлыгын арттыру;

кулланучылар кооперациясе оешмаларын мәгълүмати тәэмин итү системасын булдыру;

кулланучылар кооперациясе оешмаларын цифрлаштыру;

кулланучылар кооперациясе оешмаларының финанс тотрыклылыгын арттыру;

кулланучылар кооперациясе оешмалары хезмәткәрләренең кадрлар потенциалын һәм һөнәри белем дәрәҗәсен арттыру.

## III. Төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

3.1. Кулланучылар кооперациясен алга таба үстерү һәм аның конкурентлык сәләте күп очракта кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре эшчәнлегендә пайчылар катнашында билгеләнә. Кулланучылар кооперациясе оешмалары эшчәнлегенең барлык төрләрендә пайчыларның катнашуын активлаштыру, беренче чиратта, авыл торак пунктларында яшәүчеләрне авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималын әзерләү эшчәнлегенә, кулланучылар товарларын җитештерү, җәмәгать туклануын оештыру эшчәнлегенә максималь җәлеп итү юлы белән, шулай ук аларның «Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасының идарә органнары (Совет, Идарә, ревизия комиссиясе) эшчәнлегендә катнашуы аша активлаштыру күздә тотыла. Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерүнең төп юнәлешләре буенча карарлар кабул итүдә Совет һәм Идарәнең роле көчәю күздә тотыла.

3.2. Кулланучылар кооперациясе оешмаларының сәүдә эшчәнлегенең төп билгеләнеше булып авыл торак пунктларында яшәүчеләрне кулланучылар товарлары (беренче чиратта, беренче зарурлык товарлары) белән тәэмин итү тора.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының сәүдә эшчәнлегендә төп проблемалар булып кала:

100 кешедән кимрәк халкы булган авыл торак пунктларында урнашкан кибетләрне тотуга зур чыгымнар;

кибетләрнең товарларны күпләп сатып алу урыннарыннан шактый еракта урнашуы (шул исәптән бүлү үзәкләренең);

заманча һөнәри компетенцияләргә җавап бирә торган кадрлар җитмәү.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының сәүдә эшчәнлеген үстерүдә өстенлекле юнәлешләр булырга тиеш:

кулланучылар кооперациясе оешмаларында җитештерелә торган товарлар өчен фирма бренды булдыру;

кулланучылар кооперациясе оешмаларының товар запаслары белән тәэмин итүнең логистик системасын булдыру;

кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан үз интернет-кибетләрен булдыру, Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясе оешмалары җитештерә торган товарларны Татарстан Республикасының электрон сәүдә мәйданчыкларында сату;

халыкка комплекслы хезмәт күрсәтү пунктлары төзелешен дәвам итү;

товар ассортиментын киңәйтү, шул исәптән үз производствосы продукциясе хисабына;

авыл торак пунктларында яшәүчеләргә иң кирәк булган товарларны китерү буенча күчмә сәүдәне (автолавкаларны) саклап калу һәм үстерү;

Татарстан Республикасында оештырыла торган ярминкә чараларында катнашуны киңәйтү.

3.3. Кулланучылар кооперациясе оешмаларының әзерләү эшчәнлеген үстерүдә төп бурыч - шәхси ярдәмче хуҗалыкларда (алга таба - ШЯХ) авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималны сатып алу күләмнәрен арттыру, шулай ук авыл торак пунктларында яшәүчеләрне авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималын әзерләү эшчәнлегенә җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының хәзерләү эшчәнлеге үсешен тоткарлый торган төп проблемалар түбәндәгеләр:

шәхси ярдәмче хуҗалыклардан сатып алынган авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималны сатуның бердәм системасы булмау;

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималын сатып алу һәм саклау өчен матди-техник базаны үстерү өчен әйләнештәге чараларның җитәрлек булмавы;

шәхси ярдәмче хуҗалыклардан сатып алынган авыл хуҗалыгы продукциясе һәм чимал сыйфатының төрлелеге.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының әзерләү эшчәнлеген үстерүдә өстенлекле юнәлешләр булып түбәндәгеләр тора:

авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү һәм саклау буенча матди-техник базаны модернизацияләү: булган яшелчә-бәрәңге саклагычларны торгызу, яңаларын төзү;

шәхси ярдәмче хуҗалыклардан сатып алына торган авыл хуҗалыгы продукциясе һәм чимал күләмнәрен арттыру;

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм кыргый үсә торган чималны эшкәртү һәм сату күләмнәрен арттыру;

икътисадый актив, эшсез халыкны кыргый үсә торган чималны җыю эшчәнлегенә җәлеп итү;

өчен кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималны сатып алу буенча алып барыла торган эшләр турында халыкка мәгълүмат бирү өчен массакүләм мәгълүмат чараларыннан (радио, матбугат, телевидение, “Интернет” челтәре) файдалану һ.б.

3.4. Кулланучылар кооперациясе оешмаларының җитештерү эшчәнлеген үстерү түбәндәге юнәлешләр буенча карала:

җитештерү предприятиеләренең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру;

җитештерү эшчәнлеген әзерләү һәм сәүдә эшчәнлеге белән интеграцияләү;

булган җитештерү куәтләрен 80 проценттан да ким булмаган дәрәҗәгә кадәр тәэмин итү;

азык-төлек продукциясе җитештергәндә сыйфат һәм куркынычсызлык менеджменты системаларын кертү, шул исәптән HACCP (Hazard Analysis and Critical Control Points) принципларына нигезләнгән.

3.5. Кулланучылар кооперациясе оешмаларында җәмәгать туклануын үстерүнең төп юнәлешләре түбәндәгеләр булырга тиеш:

кулланучылар ихтыяҗы нигезендә җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеген камилләштерү, шул исәптән товарлар һәм хезмәтләрне интернет-кибетләр аша гамәлгә ашыру;

кулланучылар өстенлекләренең төрле типларына юнәлдерелгән локацияләр (урыннар/объектлар) ачу (милли кухня, яшьләр ялы, махсус туклану);

кулинария продукциясе җитештерү һәм «Кулинария» кибетләре челтәрен, мини-пекарнялар, кондитер цехларын төзү;

авыл торак пунктларында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәм гомуми белем бирү оешмаларында туклануны оештыру буенча хезмәтләр күрсәтү.

3.6. Авыл халкына көнкүрештә хезмәт күрсәтү кулланучылар кооперациясе оешмалары эшчәнлегенең кирәкле төре булып кала. Аны камилләштерү түбәндәге юнәлешләр буенча барачак:

аларга ихтыяҗ булуны исәпкә алып, комплекслы кабул итү пунктлары, стационар предприятиеләр челтәрен үстерү;

авыл торак пунктларында күчмә көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру, шулай ук заказчылар йортына, интернет кибетләр аша заказлар кабул итү һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

халыкка сезонлы хезмәт күрсәтүне оештыру (җәйге чорда дача ширкәтләрендә, язгы-җәйге кыр эшләрен уздыру һәм урып-җыю чорында);

халыкның социаль якланмаган төркемнәренә, шул исәптән ветераннарга, инвалидларга сәүдә хезмәте күрсәтүне оештыруда актив катнашу.

3.7. Кулланучылар кооперациясе оешмаларының финанс тотрыклылыгын арттыру түбәндәгеләр исәбеннән тәэмин ителәчәк:

кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан финанс, шулай ук салым һәм инвестиция сәясәтен планлаштырганда заманча алымнарны куллану;

кулланучылар кооперациясе оешмалары эшчәнлегенең барлык төрләре буенча рентабельлекнең артуы;

үз финанс ресурсларыннан (кулланучылар кооперациясе оешмалары акчаларыннан, шулай ук заемнардан һәм инвестицияләрдән) файдалану;

кулланучылар кооперациясе оешмаларына дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү.

3.8. Кулланучылар кооперациясе оешмалары эшчәнлеген сыйфатлы кадрлар белән тәэмин итү аларның тотрыклы үсешенең мөһим ресурсы булып кала.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларында кадрлар потенциалын арттыруда өстенлекле юнәлешләр булып түбәндәгеләр тора:

аларның хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләренә бәйле рәвештә хезмәткәрләрне бүләкләү системасын булдыру;

коррупциягә каршы көрәш;

социаль ярдәм чараларын күрсәтү һәм торак белән тәэмин итү;

яшь хезмәткәрләрне, шул исәптән пайчыларны әзерләү, җитештерү һәм сәүдә эшчәнлегендә актуаль проблемаларны хәл итүгә җәлеп итү;

кадрларны әзерләү, шулай ук аларны яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү;

Татарстан Республикасында һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында белгечләр әзерләүгә заказ бирү, шул исәптән Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләренең Үзәк берлеге белән хезмәттәшлектә.

## IV. Концепцияне тормышка ашыру механизмы

Концепцияне гамәлгә ашыру максатларында түбәндәге өлештә чаралар үткәрү планлаштырыла:

Татарстан Республикасында кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре системаларын, кулланучылар кооперациясенең башка оешмаларын саклап калу;

Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында авыл торак пунктларында яшәүчеләргә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималын сатып алу, эшкәртү һәм сату буенча хезмәт күрсәтүләр буенча кулланучылар кооперациясе оешмалары төзү;

стационар сәүдә объектлары булмаган авыл торак пунктларында халыкка комплекслы хезмәт күрсәтү пунктлары төзелешен дәвам итү;

Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм муниципаль районнарында ваклап сату базарларында авыл хуҗалыгы продукциясен һәм кулланучылар билгеләнешендәге товарларны сатуны оештыру;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмаларына дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү;

Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ерак урнашкан авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарлар илтү буенча ягулык-майлау материаллары чыгымнарының бер өлешен каплау

___